**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**“04” сентябрь 2018 ел** **№ 66**

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 26 июнендәге “Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү Кагыйдәләрен яңа редакциядә раслау турында”гы 63 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2017 елның 29 декабрендәге 477-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында”гы Федераль законының 15 маддәсенә үзгәреш кертү турында”гы Федераль закон нигезендә, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2017 елның 26 июнендәге 63 номерлы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган, “Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәреш кертү турында:

Кагыйдәләрнең 98.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“98.9. туктап тору территориясенә инвалидларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итү. Транспорт чараларының һәр туктау урынында, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, I, II төркем, шулай ук III төркем инвалидлар йөртә торган транспорт чараларын һәм шундый инвалидларны һәм (яисә) инвалид балаларны йөртүче транспорт чараларын түләүсез парковкалау өчен 10 процентган ким булмаган (әмма кимендә бер урын) урын бүлеп бирелә. Күрсәтелгән урыннарны парковкалау өчен башка транспорт чаралары биләргә тиеш түгел.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- ТР Кама Тамагы районы Варварино авылы, Ленин урамы, 32 йорт ;
- ТР Кама Тамагы районы, Көрәле авылы, Үзәк урам, 2а йорт;

шулай ук хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Красновидово авыл җирлеге
Советы рәисе, Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Варварино авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Т.Нотфуллин